КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июль г.Казань № 559

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында» 2017 ел, 21 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында» 2017 ел, 21 апрель, 234 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 август, 642 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1220 нче; 2020 ел, 28 февраль, 151 нче; 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 2 апрель, 209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы турындагы нигезләмәгә, 3.2 пункттагы «Татарстан Республикасы Премьер-министры» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин